| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.08.2017** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2218** |
|---|---|---|

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре һәм муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2016 елның 25 июлендәге 1946 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 02 августындагы 538 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2016 елның 27 июнендәге 438 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре һәм муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2016 елның 25 июлендәге 1946 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «2016 елның 1 июленнән 1 280,0 күләмендә өстәмә түләү» сүзләрен «2017 елның 1 июленнән 1 580,07 күләмендә өстәмә түләү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган аерым оешмаларда эшләүчеләргә компенсация түләүләренең күләмен билгеләү турында кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

3. Бу карарның көче 2017 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 17 августындагы 2218 номерлы карарына кушымта

Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә компенсация түләүләре күләмнәре

| Бердәм тариф челтәренең хезмәт өчен түләү разрядлары | Компенсация түләүләре күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 3383 |
| 2 | 3283 |
| 3 | 3193 |
| 4 | 3082 |
| 5 | 2805 |
| 6 | 2780 |
| 7 | 2704 |
| 8 | 2692 |
| 9 | 2692 |
| 10 | 2680 |
| 11 | 2673 |
| 12 | 2673 |
| 13 | 2673 |
| 14 | 2673 |
| 15 | 2673 |
| 16 | 2673 |
| 17 | 2673 |
| 18 | 2673 |